РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» декабрь 2023г. г. Альметьевск № 134

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 152 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законнар нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» 2014 елның 19 ноябрендәге 152 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы карарына кушымтага (2015 елның 23 октябрендәге 10 номерлы, 2016 елның 6 октябрендәге 46 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 59 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 138 номерлы, 2019 елның 29 апрелендәге 151 номерлы, 2019 елның 25 октябрендәге 174 номерлы, 2021 елның 12 маендагы 30 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 50 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 72 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 94 номерлы, 2023 елның 17 маендагы 110 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 111 номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 120 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 12 статьясындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның резерв фонды күләме шәһәр бюджеты турында шәһәр Советы карары белән билгеләнә.».

2. 2024 елның 1 январеннан 2025 елның 1 яннварена кадәр 1 бүлекнең 19.1 статьясының 3 пунктының, 19.2 статьясының 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга (муниципаль гарантияләрне бюджет турындагы карар нигезендә бирү өлешендә).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр башлыгы Т.Д. Нагуманов